РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 50

2018 елның 28 ноябре

**Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәләре чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 16 июнендәге 19/1 номерлы, «Түбән Кама шәһәренең Территориаль иҗтимагый үзидарәләре уставларын теркәү турында» 2008 елның 25 июлендәге 19/2 номерлы карарына өстәмәләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Түбән Кама шәһәр Советының 2008 елның 5 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган, Түбән Кама шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәләрне оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе һәм территориаль иҗтимагый үзидарәләр уставын теркәү тәртибе нигезендә, территориаль иҗтимагый үзидарәләр гамәлгә ашырылмый торган шәһәрнең торак территорияләре (микрорайоннар) артуга бәйле рәвештә, Түбән Кама шәһәр Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәләре чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 16 июнендәге 19/1 номерлы карарының 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:

«Территориаль иҗтимагый үзидарә чикләрен билгеләргә:

- 47, 49нчы микрорайоннар гражданнарның түбәндәге яшәү территорияләре чикләрендә:

Фикрәт Тәбиев урамы чикләре – Корабельная урамы – Тынычлык проспекты – Төзүчеләр проспекты».

2. Түбән Кама шәһәр Советының «Түбән Кама шәһәренең Территориаль иҗтимагый үзидарәләре уставларын теркәү турында» 2008 елның 25 июлендәге 19/2 номерлы карарының 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле текст белән тулыландырырга:

«47, 49нчы микрорайоннарның территориаль иҗтимагый үзидарә уставын теркәргә».

2.1. Түбән Кама шәһәренең территориаль иҗтимагый үзидарәләр уставлары Реестрына тиешле язуны кертергә

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының регламент, җирле үзидарә һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин